КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1113

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нче, 2017 ел, 21 март, 167 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, преамбулада һәм 1 пунктта «(конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар)» сүзләрен «(семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә, 1 һәм 2 пунктларда «(конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар)» сүзләрен «(семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

дүртенче һәм бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юк;»;

алтынчы абзацта «һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре булмаска тиеш» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алырга тиеш түгел.»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«чаралар оештыру һәм үткәрү өчен граждан-хокук шартнамәләре нигезендә, шул исәптән автор шартнамәләре нигезендә җәлеп ителгән белгечләр хезмәте өчен түләүгә чыгымнар;

чыгым материалларына түләүгә чыгымнар;

белем бирү программаларын эшләү һәм үткәрү хезмәтләренә түләүгә чыгымнар.»;

6 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы үзгәртеп төзү, бетерү, банкротлы процессында булмау турында субсидия алучы җитәкчесе имза куйган гарантияле хат;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«оешма әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормауны раслый торган документлар;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юклыкны раслый торган документлар.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Юридик затлар үз теләкләре белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне;

субсидия алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият түләүләре, пенеләр, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмауны раслый торган салым органы белешмәсе.»;

17 пунктның өченче абзацында «субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, тәртибе һәм вакытлары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

20.1 пунктның үз көчен югалтуын танырга;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

санлы атамасында исемендә, 1 һәм 2 пунктларда «(конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар)» сүзләрен «(семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар)» сүзләренә алмаштырырга;

4 пункттагы таблицада «Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә салымнар түләү» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «аралар оештыру һәм үткәрү өчен граждан-хокук шартнамәләре нигезендә, шул исәптән автор шартнамәләре нигезендә җәлеп ителгән белгечләр хезмәте өчен түләүгә чыгымнар; | |
| чыгым материалларына түләүгә чыгымнар; | |
| белем бирү программаларын эшләү һәм үткәрү хезмәтләренә түләүгә чыгымнар». | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин